**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**16нчы май, 2022ел** **№ 167**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен кабул итү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Советның 2019 елның 17 августындагы 314 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан аның составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешү төзү тәртибе, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре вәкиллекле органнарыннан әлеге авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырылган җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен кабул итәргә:

- тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү буенча;
- җир эшләрен җитештерүгә рөхсәт бирү буенча;
- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына, районның Административ-техник инспекциясе йөзендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында төзелүче килешүләрнең гамәлдә булуы 2022 елның 1 нче майдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын күздә тотып килешү төзергә.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: http://vysokaya-

gora.tatarstan.ru адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш.Шакиров